# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТРУДОЛЮБОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**№ 16** **16 июнь2015 ел**

**Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны билгеләү турында**

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлешенә, 105 статьясындагы 1 өлешенә, «Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына ярашлы рәвештә, Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлеге Советы карары:

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2015 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча «Сельская Новь» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга. http://Aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Трудолюбово авыл җирлеге
Советы Рәисе Р.К.Канафин